КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 13 март г.Казань № 149

Татарстан Республикасының калдыклар белән, шул исәптән каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә территориаль схемасын раслау турында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 ел, 24 июнь, ФЗ-89 нчы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Калдыклар белән, шул исәптән каты коммуналь калдыклар белән эш итүнең территориаль схемалары составына һәм эчтәлегенә карата таләпләрне раслау турында» 2016 ел, 16 март, 197 нче карары, Татарстан Республикасы Экология кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасының калдыклар белән, шул исәптән каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә территориаль схемасын (алга таба – Территориаль схема) расларга.
2. Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнарына муниципаль берәмлекләрне территориаль планлаштыру документларын, муниципаль берәмлекләр территорияләрен чистартуның генераль схемаларын бу карар белән расланган Территориаль схеманы исәпкә алып тәгаенләштерүне тәкъдим итәргә.
3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында калдыклар белән, шул исәптән каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә территориаль схеманы раслау турында» 2016 ел, 26 сентябрь, 683 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.
4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин